СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с. Нижние Метески,Арский
муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

---

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“22” сентябрь 2020 ел** **№7**

Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk/tatarstan.ru).

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Арча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 22.09.2020 ел, №7 карары белән РАСЛАНГАН

Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары (алга таба –Җирлек) һәм Арча муниципаль районы (алга таба - Район) җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары Район җирле үзидарә органнары белән әлеге җирлекләр бюджетларыннан Россия Федерациясе бюджет кодексы нигезендә район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен аларга тапшыру турында Район Советы карары белән расланган формада килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта Районның җирле үзидарә органнары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, җирле үзидарә органнарына җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә җирлек территориясендә шәһәр һәм авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Җирлек һәм Районның җирле үзидарә органнары тапшыра ала.

4. Авыл җирлеге башкарма комитеты үз инициативасы белән яисә Районның җирле үзидарә органнары инициативасын карап, 30 көн эчендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында Җирлек Советы карары проектын әзерли.

5. Авыл җирлеге башкарма комитеты Җирлек Советына норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Җирлек Советы карары проектын кертә.

6. Җирлек Советы Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Район җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.

7. Авыл җирлеге Советы карары уңай каралганда, Җирлек җирле үзидарә органнары һәм Районның җирле үзидарә органнары арасында Килешү төзелә.

Әлеге Килешү билгеле бер вакытка төзелергә, аның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен, шул исәптән әлеге өлештә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибен, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган нигезләмәләрне, шулай ук Килешүне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен һәр яктан тигез санда вәкилләрне кертеп, эшче төркем төзелергә мөмкин. Эшче төркем үз эше нәтиҗәләре буенча Килешү якларының мәнфәгатьләрен максималь рәвештә исәпкә ала торган Килешү проектын әзерли.

8. Әгәр Җирлек Советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Район җирле үзидарә органнарына тапшыру турындагы карар проектын кире какса, алар керткән мәсьәлә буенча карау нәтиҗәләре турында хат җибәрелә.

9. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган очракта, алар Җирлек бюджетына ун көнлек срокта кире кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатыннан, бюджет законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар каралган Район һәм Җирлекләр бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

Бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, шул ук вакытта финанс чараларының барлык суммасын бер үк вакытта күчерү мөмкин.

10. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, муниципаль милек түләүсез ашыгыч файдалану килешүе нигезендә тапшырыла. Түләүсез файдалану килешүе тиз арада һәм килешү гамәлдә булу срогына төзелә.

11. Әлеге Килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Арча район Советы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә Районның җирле үзидарә органнары үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

12. Вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны сорый.

13. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатылырга мөмкин:

- Якларның үзара килешүе буенча;
- берьяклы тәртиптә, бер як үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

14. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Район җирле үзидарә органы вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән файдаланылмаган финанс чараларын, матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

15. Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедуралары юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.